МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

16.12.2019 Казан ш. № под-1844/19

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт аккредитациясе булган төп гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы хосусый мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында мәктәпкәчә белем, хосусый гомуми белем бирү оешмаларында һәм шәхси эшкуарлар тарафыннан мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем алуны финанслар белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2017 елның 9 мартындагы 132 номерлы карарын гамәлгә ашыру максатларында эш оештыру турында» 2017 елның 20 мартындагы под-448/17 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

«2020 елга Татарстан Республикасында мәктәпкәчә белем бирү буенча белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында» 2019 елның 2 октябрендәге 77-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә:

1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт аккредитациясе булган төп гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы хосусый мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында мәктәпкәчә белем, хосусый гомуми белем бирү оешмаларында һәм шәхси эшкуарлар тарафыннан мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем алуны финанслар белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2017 елның 9 мартындагы 132 номерлы карарын гамәлгә

ашыру максатларында эш оештыру турында» 2017 елның 20 мартындагы под-448/17 номерлы боерыгына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

хосусый мәктәпкәчә белем бирү оешмаларына, хосусый гомуми белем бирү оешмаларындагы мәктәпкәчә төркемнәргә, шәхси эшкуарларга субсидия күләмен хисаплап чыгару формасын яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә);

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча министрның беренче урынбасары И.Г.Хәдиуллинны җаваплы итеп билгеләргә.

2. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән башлап үз көченә керә һәм 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары –
министр Р.Т. Борһанов

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2017 елның 20 мартындагы под-448/17 номерлы боерыгы белән расланды (Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 16.12.2019 под-1844/19 номерлы боерыгы редакциясендә)

**Хосусый мәктәпкәчә белем бирү оешмаларына, хосусый гомуми белем бирү оешмаларындагы мәктәпкәчә төркемнәргә, шәхси эшкуарларга субсидия күләмен хисаплап чыгару формасы**

| Хосусый мәктәпкәчә белем бирү оешмасы, хосусый гомуми белем бирү оешмасында мәктәпкәчә төркемнәр, шәхси эшкуар | Төркемнең юнәлеше (гомуми үстерү, компенсацияләүче, катнаш, савыктыру) | Авыл җирлеге/шәһәр округы (шәһәр/шәһәр округы, авыл) | Тәрбияләнүчеләр-нең яшь составы (өч яшькә кадәр, өч яшьтән олырак) | Эш режимы (5, 6 көнлек, эш сәгатьләре саны) | Төркем-нәр саны | Тәрбия-ләнүчеләр саны |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |
| | | | | | | |

Җитәкче __________-. (ФИА) телефон № ______
Башкаручы ____________________ телефон № _______________ дата _______________ 20___ ел